**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Тутай авыл җирлеге Советы**

# Карары

10 сентябрь 2018 ел №101

**Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советы депутатының статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 ечы статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Тутай авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 августындагы 65 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советы депутатының статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

13 нче статьяны һәм 14 нче статьяның 2 нче, 3 нче пунктларын көчен югалткан дип санарга.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Җирлек башлыгы** **Насретдинова Н.М**